

1971елда кечкенэ Әлфия Балтач урта мәктэбенә 1 класска укырга керә. Мәктәп елларыннан ук Әлфия рухи яктан гына тугел, ә физик яктан да нык була.1985 елда Арча егете Тәлгать белән тормыш корып җибәрәләр. Бер-бер артлы уллары һәм кызлары туа. Үзенең көрәш алымнарын үстерә барып, Сабантуйларда беренчелекне бирми, Татарстан бәйгесендә сынала, ә аннан сон ин көчлеләр рәтендә рәсәй күләмендәге бәйгеләрдә дә катнаша. Әлфия Зиатдинова Татарстан командасы составында Рәсәебезнен 17 шәһәрендә чыгыш ясап “Рәсәйнең спорт остасы” исеменә лаек була. Әлфия уз уңышлары белән генә чикләнми, районда да кул көрәше спортын үстерергә тели, балалар һәм зурлар өчен түгәрәкләр оештыра. Күп еллар дәвамында Әлфия апа кул көрәше белән беррәттән чаңгы, җиңел атлетика, баскетбол, волейбол уеннарында җитезлеге белән алдыра. Волейбол буенча район хатын-кызлар җыелма командасын җитәкли. Шулай ук Әлфия мәктәп һәм мәдәни чараларда еш чыгышлар ясый, спортнын ихлас пропагандисты санала, патриотик тәрбиягә дә зур өлеш кертә. Бугенге көндә Әлфия ханым 2 баласына кадерле әни, оныкларына яраткан дәү эни, эшендә үрнәк хезмәткәр, туганнарына терәк булып, Ходай биргән һәр көнгә шөкер итеп яши.

